## IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ XIII СЕССИЯСЕ

## К А Р А Р №74

Мөслим авылы «14» декабрь 2021 ел

**Мөслим муниципаль районы территориясендә аренда хокукында инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә җир кишәрлекләрен беренче чиратта бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы, Татарстан Республикасы Җир кодексы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен бирү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Мөслим муниципаль районы территориясендә аренда хокукында инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә җир кишәрлекләрен беренче чиратта бирү тәртибе турындагы нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) расларга.
2. Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетына җир кишәрлекләре бирү өлкәсендә хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы үз норматив хокукый актларын әлеге Нигезләмәгә туры китерергә.
3. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Мөслим муниципаль районының мәгълүмат сайтында урнаштырырга.

Мөслим муниципаль районы
Башлыгы урынбасары,
Мөслим муниципаль районы
Советы рәисе урынбасары А.М.Әхмәтҗанов

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
Советының 2021 елның 14 ноябрендәге
74 нче номерлы карарына кушымта

## Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы территориясендә инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә җир кишәрлекләрен беренче чиратта аренда хокукында бирү тәртибе турында нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә (алга таба – инвалидлар, яки мөрәҗәгать итүчеләр) Татарстан Республикасының «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге җир кишәрлекләрен һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык (алга таба - җир кишәрлекләре) максатлары өчен беренчел чиратта аренда хокукында бирү тәртибен җайга сала.

1.2. Җир кишәрлекләрен бирү Россия Федерациясе Җир кодексы, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында», 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» федераль законнар, Татарстан Республикасы Җир кодексы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрендә җирләр бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Уставы белән әлеге Нигезләмәдә каралганча тормышка ашырыла.

1.3. Җир кишәрлекләрен бирү тиешле гаризалар нигезендә Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

1.4. Мөслим муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы мөрәҗәгать итүчеләргә җир кишәрлекләрен арендалау хокукында беренче чиратта бирү турындагы карар проектын әзерли.

1.5. Мөрәҗәгать итүчегә беренче чиратта бирү өчен җир кишәрлеген формалаштыру мөрәҗәгать итүче тарафыннан тәэмин ителә һәм мөрәҗәгать итүче акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

1.6. Бер үк җир кишәрлегенә карата берничә гариза кергән очракта, соралган җир кишәрлеген бирү турындагы карар мөрәҗәгать итүче файдасына кабул ителә.

1.7. Әгәр бер үк җир участогына карата төрле мөрәҗәгать итүчеләрдән берничә гариза килгән булса, соралган җир кишәрлеген бирү турындагы карар ин беренче гариза биргән зат файдасына кабул ителә.

### 2. Инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә җир кишәрлекләрен бирү шартлары

2.1. Җир кишәрлекләре гариза биргән датага түбәндәге шартларга җавап биргән мөрәҗәгать итүчеләргә аренда хокукында бирелә:

2.1.1. инвалид булган гражданин һәм составында инвалид булган гаилә әгъзаларының барысы да Россия Федерациясе гражданнары булып тора һәм Мөслим муниципаль районы составына керүче җирлек территориясендә даими яшәү урыны буенча теркәлгән;

2.1.2. медик-социаль экспертиза дәүләт хезмәте учреждениесеннән бирелгән инвалидлыкны билгеләү фактын раслый торган белешмә;

2.1.3. инвалид булган гражданин һәм составында инвалид булган гаилә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәптә тора;

2.1.4. инвалид булган граждан һәм үз составында инвалид булган гаилә әгъзалары «Мөслим муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ тарафыннан алып барыла торган чиратта торалар.

2.1.5. инвалид булып торучы гражданин һәм составында инвалид булган гаилә әгъзалары милек, даими (сроксыз) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлек мирас итеп алу, торак төзелеше белән бәйле максатлар өчен бирелгән җир кишәрлеген арендалау хокукына ия түгелләр (шул исәптән рөхсәт ителгән түбәндәге төрләре белән: индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык, яшелчәчелек);

2.1.6. инвалид булган гражданин һәм составында инвалид булган гаилә әгъзалары гариза биргән датага соңгы ике ел дәвамында милек хокукын тартып алу, җир кишәрлегенә хокукларны тапшыру (җир кишәрлегенең, җир кишәрлекләренең бер өлеше) буенча әлеге Нигезләмәнең 2.1.5 пунктында күрсәтелгән алыш-бирешне башкармаган.

2.2. 2.1.5 һәм 2.1.6 пунктлары индивидуаль торак төзелеше өчен бирү максатларында муниципаль берәмлекләрнең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән расланган иң минималь чик күләменнән кимрәк булган очракта кулланыла алмый..

2.3. Җир кишәрлекләре беренче чиратта даими яшәү урыны буенча теркәлгән мөрәҗәгать итүчеләргә Мөслим муниципаль районы составына керә торган җирлек җирләре чикләрендә бирелә

2.4. Мөрәҗәгать итүчеләргә беренче чиратта бирелә торган җир кишәрлегенең минималь һәм максималь күләме муниципаль берәмлекләрнең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә билгеләнә.

2.5. Мөрәҗәгать итүчеләргә җир кишәрлекләре беренче чиратта бер тапкыр гына бирелә.

## 3. Инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә җир кишәрлекләрен беренче чиратта бирү тәртибе

3.1. Җир кишәрлекләре мөрәҗәгать итүчеләргә, сату (аукцион) үткәрмичә генә, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.6 ст., 2 бүл. 14 п., 39.14 ст., 39.15 ст., 39.16 ст., 39.17 ст., нормалары нигезендә, беренче чиратта арендага түбәндәге очракларда бирелә:

1) җир кишәрлеге төзелергә тиеш булса һәм чикләрендә шундый җир кишәрлеге төзелергә тиешле территорияне ызанлау проекты расланмаган очракта җир кишәрлеген урнаштыру схемасын әзерләү;

2) вәкаләтле органга (Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетына) җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында гариза бирү, әгәр җир кишәрлеген төзергә яки җир кишәрлеге чикләре «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль закон нигезендә төгәлләштерелергә тиеш булса;

3) җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү турында карар кабул итү;

4) мөрәҗәгать итүче тарафыннан җир кишәрлеген төзү максатларында җир кишәрлеген межалау проекты, җир кишәрлеген яки кадастр эшләрен урнаштыру схемасы белән, җир кишәрлеге чикләрен төгәлләштерү өчен кирәк булган кадастр эшләрен башкаруны тәэмин итү (җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында Карар кабул ителгән очракта);

5) җир кишәрлегенең дәүләт кадастр исәбен гамәлгә ашыру яисә җир кишәрлеге чикләрен төгәлләштерүгә бәйле рәвештә дәүләт кадастр исәбенә алу;

6) вәкаләтле органга (Мөслим муниципаль районы башкарма комитетына) җир кишәрлеге бирү турында гариза бирү;

7) җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү.

3.1.1. Җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү турында гариза, җир кишәрлеген бирү турында гариза мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан үз теләкләре белән кәгазь чыганакта почта элемтәсе аша яки «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, электрон документлар рәвешендә вәкаләтле органга (Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетына) тапшырыла яки җибәрелә. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен кулланып, электрон документ формасында бирелгән очракта, әлеге гаризаларны бирү тәртибе һәм ысуллары, аларның форматына карата таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана.

3.1.2. Мөрәҗәгать итүче ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән вәкаләтле орган (Мөслим муниципаль районы башкарма комитеты) тарафыннан алынырга тиешле документларны тапшырырга хокуклы.

3.2. Мөрәҗәгать итүчеләргә җир кишәрлекләрен арендага бирү муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча административ регламентлар нигезендә гамәлгә ашырыла: Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты; Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сату үткәрмичә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты.

3.3. Беренче чиратта бирелгән җир кишәрлекләре өчен мөрәҗәгать итүчеләргә аренда түләве күләме Россия Федерациясе Җир кодексының 39.7 ст. 5 бүлегенең 3 пункты нигезендә исәпләнә.